РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АЛЕКСЕЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САХАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
Мирная ул., д. 100, с. Сахаровка, 422931
тел.: (84341)3-40-44, факс: (84341)3-40-44,
ОКПО 93066517, ОГРН 1061677002870,
ИНН/КПП 1605004877 / 160501001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
САХАРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тынычлык ур., 100 нче йорт, Сахаровка, 422931
тел.: (84341)3-40-44, факс: (84341)3-40-44,
ОКПО 93066517, ОГРН 1061677002870,
ИНН/КПП 1605004877 / 160501001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**14.03.2024 г.** **с.Сахаровка** **№ 13**

**«Җирлекнең Генераль планыннан яки җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләреннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 27.12. 2021 ел, № 20 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карарына таянып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахаровка авыл җирлеге Башкарма комитетының 27.12.2021 ел, № 20 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахаровка авыл җирлегенең Генераль планыннан яисә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләреннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан сорауның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында башкарыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон

формадагы сорау кыры ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон формасындагы мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахаровка авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы** **К.А.Мигушина**